**ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**420111,г.Казань, ул. Б. Красная, 15/9**
**тел. 236-91-44**
**E-mail: tatgi@tatar.ru**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ**

**420111, Казан шәһәре, Б. Красная ур. 15/9**
**тел. 236-91-44**
**E-mail: tatgi@tatar.ru**

№ 151

П Р И К А З | Б О Е Р Ы К

«15» 11 2013ел.

Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлек алып баручы махсуслаштырылган коммерцияле булмаган оешма (өлкәара оператор) һәм махсус исәп хуҗасы тарафыннан белешмәләр тапшыруның Тәртибен раслау турында

25.06.2013 ел, 52-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларның гомуми милкенә капиталь ремонт үткәрүне оештыру турында”гы Татарстан Республикасы законының 12 статьясының 3 өлешен үтәү максатында, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлек алып баручы махсуслаштырылган коммерцияле булмаган оешма (өлкәара оператор) һәм махсус исәп хуҗасы тарафыннан белешмәләр тапшыруның теркәлүче Тәртибен расларга.
2. Капиталь ремонт буенча дәүләт программасының формалашуын һәм үтәлешен мониторинглауның һәм торак фонды объектларының торышын мониторинглауның интеграцияләнгән мәгълүмати-аналитик системасын (https://bars-monjf.tatar.ru/monjf/) - күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлек алып баручы махсуслаштырылган коммерцияле булмаган оешма (өлкәара оператор) һәм махсус исәп хуҗасы тарафыннан 25.06.2013 ел, 52-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларның гомуми милкенә капиталь ремонт үткәрүне оештыру турында”гы Татарстан Республикасы законының 12 статьясының 3 өлешендә каралган белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән мәгълүмат системасы белән билгеләргә.
3. Әлеге Боерык белән Инспекция башлыгы урынбасарларын, бүлек башлыкларын һәм Инспекция хезмәткәрләрен имзалатып таныштырырга.
4. Хокукый идарәгә әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында тиешле тәртиптә теркәлүен үткәрергә.
5. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башлык Крайнов С.А.

Татарстан Республикасының
Дәүләт торак инспекциясе башлыгы
боерыгы белән расланды
«15» 11 2013 № 151

Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә
күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлек алып баручы махсуслаштырылган коммерцияле булмаган оешма (өлкәара оператор) һәм махсус исәп хуҗасы тарафыннан белешмәләр тапшыруның
ТӘРТИБЕ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлек алып баручы махсуслаштырылган коммерцияле булмаган оешма (өлкәара оператор) һәм махсус исәп хуҗасы тарафыннан белешмәләр тапшыруның әлеге Тәртибе 25.06.2013 ел, 52-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларның гомуми милкенә капиталь ремонт үткәрүне оештыру турында”гы Татарстан Республикасы законының 12 статьясының 3 өлешен үтәү максатында эшләнде.

1.2. Тәртиптә түбәндәге төп терминнар һәм төшенчәләр кулланыла:

күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлек алып баручы махсуслаштырылган коммерцияле булмаган оешма – фондның оешу-хокукый формасында булдырылган юридик заты (функцияләре Россия Федерациясе Торак кодексының 180 статьясы белән билгеләнгән) (алга таба – өлкәара оператор);

махсус исәп хуҗасы – торак милекчеләре ширкәте, торак кооперативы яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы (банктагы махсус исәп Россия Федерациясенең Гражданнар кодексы һәм Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән үзенчәлекләр нигезендә ачыла);

ТФМ МАС – капиталь ремонт буенча дәүләт программасының формалашуын һәм үтәлешен мониторинглауның һәм торак фонды объектларының торышын мониторинглауның интеграцияләнгән мәгълүмати-аналитик системасы (электрон адресы: https://bars-monjf.tatar.ru/monjf/);

капиталь ремонт фонды – күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт өчен түләнгән кертемнәр, мондый биналарның милекчеләре тарафыннан үзләренең капиталь ремонт кертемнәрен түләү йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәве сәбәпле түләнгән процентлары, махсус исәптәге акча чараларын файдаланудан өстәлгән процентлар;

күпфатирлы йортларның капиталь ремонт фондын булдыру – күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләренең, капиталь ремонт фондын өлкәара операторга карата йөкләмәләре рәвешендә булдыру максатларында, капиталь ремонт өчен кертемнәрне өлкәара оператор исәбенә күчерүе һәм, капиталь ремонт фондын махсус исәптәге акча чаралары рәвешендә булдыру максатларында, капиталь ремонт өчен кертемнәрне махсус исәпкә күчерүе;

фондны булдыруның милекчеләр тарафыннан сайланган махсус исәптәге ысулы турында белдермәнамә – тиешле күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре тарафыннан сайланган капиталь ремонт фондын булдыруның махсус

исәпле ысулы турындагы белдермәнамәне үз эченә алган, имзаланган һәм мөһер белән расланган документ, махсус исәп хуҗасы аны махсус исәп ачылганнан соң биш эш көне дәвамында билгеләнгән формада (1 нче номерлы Кушымта), аңа биналарның милекчеләренең гомуми җыелыш карары беркетмәсе күчермәсен, капиталь ремонт фондын булдыруга банкта махсус исәп ачылу турындагы белешмәне мәҗбүри теркәп, ТР ДТИ тапшырырга тиеш;

махсус исәп ачылу турында хәбәр – күпфатирлы йортта капиталь ремонт фондын булдыруның биналарның милекчеләре тарафыннан сайланган махсус исәпле ысулы турындагы белдермәнамә белән берлектә ТР ДТИ юллана торган махсус исәп ачылу турындагы банк белешмәсенең күчермәсе;

түләү йөкләмәсе – исәп хуҗасының үзенә хезмәт күрсәтүче банкка билгеле бер акча суммасын чараларны алучы исәбенә күчерү турындагы исәп-хисап документы белән рәсмиләштерелгән әмернамәсе (биналарның милекчеләреннән капиталь ремонт өчен махсус исәпле капиталь ремонт фондын булдыручы кертемнәрнең күчүен раслаучы документлар);

белдермәнамәләр реестры – ТР ДТИ тарафыннан алынган күпфатирлы йортта капиталь ремонт фондын булдыруның биналарның милекчеләре сайлаган махсус исәпле ысулы турындагы барлык белдермәнамәләрнең реестры;

махсус исәпләр реестры – капиталь ремонт фондын булдыруга билгеләнгән махсус ачык исәпләрнең реестры;

капиталь ремонт фондын булдыру ысулы сайланмаган күпфатирлы йортлар турында белешмәләр – башкарма хакимиятнең Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль оешмаларның социаль-икътисади үсеше, төзелеш, архитектура, шәһәр төзелеше һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм башкару һәм норматив-хокукый көйләү функциясен башкаручы федераль органына, шулай ук җирле үзидарә органына һәм өлкәара операторга ТР ДТИ тарафыннан юллана торган, ТФМ МАС алынган капиталь ремонт фондын булдыру ысулын сайламаган күпфатирлы йортлар турындагы мәгълүмат.

## 2. ТФМ МАС бурычлары

2.1. ТФМ МАС бурычларына түбәндәгеләр керә:

а) тиешле күпфатирлы йортта капиталь ремонт фондын булдыруның биналарның милекчеләре сайлаган махсус исәпле ысулы турындагы белдермәнамәләрне реестр рәвешендә исәпкә алу;

б) күпфатирлы йортларның махсус исәпләрен реестр рәвешендә исәпкә алу;

в) биналарның милекчеләреннән капиталь ремонт өчен махсус исәпле капиталь ремонт фондын булдыручы кертемнәрнең күчүе турындагы белешмәләрне исәпкә алу;

г) махсус исәпле капиталь ремонт фондын булдыручы күпфатирлы йортларның махсус исәбендәге чараларның калдык өлеше турындагы белешмәләрне исәпкә алу;

д) биналарының милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт фондлары исәптә, өлкәара оператор исәпләрендә булдырылган күпфатирлы йортлар турындагы белешмәләрне исәпкә алу;

е) капиталь ремонт фондларын исәптә, өлкәара оператор исәпләрендә булдыручы күпфатирлы йортлардагы биналарның милекчеләреннән капиталь ремонт кертемнәренең күчүе турындагы белешмәләрне исәпкә алу;

ж) биналарының милекчеләре капиталь ремонт фондын булдыруның ысулын сайламаган һәм (яки) аны тормышка ашырмаган күпфатирлы йортлар турында җирле үзидарә органын һәм өлкәара операторны мәгълүматлаштыру өчен җыелма хисапны формалаштыру;

з) башкарма хакимиятнең Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль оешмаларның социаль-икътисади үсеше, төзелеш, архитектура, шәһәр төзелеше һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм башкару һәм норматив-хокукый көйләү функциясен башкаручы федераль органына мәгълүмат җиткерү максатында ТР ДТИ эшчәнлегенең капиталь ремонт фондын булдыруны күзәтү өлешендәге җыелма хисапларны формалаштыру.

## 3. Күпфатирлы йортларның капиталь ремонт фонды булдырылуы турындагы мәгълүматны кертү тәртибе

3.1. Өлкәара оператор, махсус исәпләрнең хуҗалары капиталь ремонт фондын булдыру буенча мәгълүматны ай саен хисап ае артыннан килүче айның 1 нче көненә кадәр ТФМ МАС системасына кертә.

3.2. Махсус исәпнең хуҗасы теркәлүче формаларга (1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче номерлы Кушымталар) нигезләнеп, махсус исәпле капиталь ремонт фондын булдыру карары кабул ителгәннән соң биш эш көне дәвамында тиешле күпфатирлы йортта капиталь ремонт фондын булдыруның биналарның милекчеләре тарафыннан сайланган ысулы турындагы белдермәнамәне; фондны булдыру ысулын сайлау буенча биналарның милекчеләренең гомуми җыелышлары беркетмәләре күчермәләрен; күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан идарә итүнең ысулын сайлау буенча гомуми җыелыш беркетмәсе күчермәсен; күпфатирлы йорт турындагы белешмәләрне (катлылык, күпфатирлы йортның гомуми мәйданы, күпфатирлы йорттагы торак биналарның мәйданы, фатирлар саны, күпфатирлы йортта теркәлүче гражданнарның саны, файдалануга тапшырылу елы, соңгы капиталь ремонтның үткәрелү елы һ.б.); капиталь ремонт өчен махсус исәпле капиталь ремонт фондын булдыручы кертемнәрнең биналарның милекчеләреннән күчүен раслаучы документларны; биналарның милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт өчен кертемнәрнең күчүе һәм махсус исәптәге чараларның калдык өлеше турындагы белешмәләрне ТФМ МАС системасында урнаштыра.

Шулай ук, махсус исәп ачылганнан соң биш эш көне дәвамында тиешле күпфатирлы йортта капиталь ремонт фондын булдыруның биналарның милекчеләре тарафыннан сайланган ысулы турындагы белдермәнамәне, әлеге күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләренең капиталь ремонт фондын булдыру ысулын сайлавы буенча карар кабул итүгә карата гомуми җыелышлары беркетмәләрен, махсус исәп ачылу турындагы банк белешмәсенең күчермәсен теркәп, кәгазь йөрткечтә тапшыра.

3.3. Идарәче оешма (ИК, ТМШ, ТТК), яисә йорт советы рәисенең вәкиле (йорт белән турыдан-туры идарә итү) теркәлүче формаларга (1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче, 5 нче номерлы Кушымталар) нигезләнеп, өлкәара оператор исәбендәге капиталь ремонт фондын булдыруны сайлау карары кабул ителгәннән соң биш эш көне дәвамында тиешле күпфатирлы йортта капиталь ремонт фондын булдыруның биналарның милекчеләре тарафыннан сайланган ысулы турындагы белдермәнемәне; капиталь ремонт фондын булдыруның ысулын сайлау буенча биналарның милекчеләренең гомуми җыелыш беркетмәсе күчермәсен; реквизитларын күрсәтеп, исәп, өлкәара оператор исәпләре ачылу турындагы

белешмәне; күпфатирлы йортта идарә итү ысулын сайлау буенча биналарның милекчеләренең гомуми җыелышлары беркетмәләренең күчермәләрен; күпфатирлы йорт турындагы мәгълүматларны (катлылык, күпфатирлы йортның гомуми мәйданы, күпфатирлы йорттагы торак биналарның мәйданы, фатирлар саны, күпфатирлы йортта теркәлүче гражданнарның саны, файдалануга тапшырылу елы, соңгы капиталь ремонтның үткәрелү елы һ.б.); капиталь ремонт фондын булдыру һәм капиталь ремонт үткәрүне оештыру турындагы килешүнең күчермәсен; исәпкә, өлкәара оператор исәпләренә капиталь ремонт өчен биналарның милекчеләре керемнәренең күчүен раслаучы документларны; капиталь ремонт өчен биналарның милекчеләре керемнәренең күчүе турындагы мәгълүматны ТФМ МАС системасында урнаштыра.

3.4. Идарәче оешма (ИК, ТМШ, ТТК), яисә йорт советы рәисенең вәкиле (йорт белән турыдан-туры идарә итү) теркәлүче формаларга (2 нче, 4 нче номерлы Кушымталар) нигезләнеп, өлкәара оператор исәбендәге капиталь ремонт фондын булдыруны сайлау карары кабул ителгәннән соң биш эш көне дәвамында капиталь ремонт фондын булдыру ысулын сайлау буенча милекчеләрнең гомуми җыелышлары беркетмәләренең күчермәләрен; күпфатирлы йортта идарә итү ысулын сайлау буенча биналарның милекчеләренең гомуми җыелышлары беркетмәләренең күчермәләрен; капиталь ремонт фондын булдыру һәм капиталь ремонт үткәрүне оештыру турындагы килешүнең күчермәсен; күпфатирлы йорт турындагы белешмәләрне (катлылык, күпфатирлы йортның гомуми мәйданы, күпфатирлы йорттагы торак биналарның мәйданы, фатирлар саны, күпфатирлы йортта теркәлүче гражданнарның саны, файдалануга тапшырылу елы, соңгы капиталь ремонтның үткәрелү елы һ.б.); капиталь ремонт өчен биналарның милекчеләре кертемнәренең күчүе турындагы белешмәләрне ТФМ МАС системасында урнаштыра.

3.5. Әгәр дә күпфатирлы йортта капиталь ремонт фондын булдыруның ысулы биналарның милекчеләре тарафыннан сайланмаган булса, җирле үзидарә органы мондый йортка карата өлкәара оператор исәбендәге капиталь ремонт фондын булдыру карарын кабул итә. Идарәче оешма (ИК, ТМШ, ТТК), яисә йорт советы рәисе (турыдан-туры идарә итү очрагында) өлкәара исәбендәге капиталь ремонт фондын булдыруны сайлау турындагы карар кабул ителгәннән соң биш эш көне дәвамында җирле үзидарә органының мондый йортка карата өлкәара оператор исәбендәге капиталь ремонт фондын булдыру карарын раслаучы документның күчермәсен; күпфатирлы йортта идарә итү ысулын сайлау буенча биналарның милекчеләренең гомуми җыелышлары беркетмәләре күчермәләрен; капиталь ремонт фондын булдыру һәм капиталь ремонт үткәрүне оештыру турындагы килешүнең күчермәсен ТФМ МАС системасында урнаштыра.

3.6. ТР ДТИ теркәлүче формаларга (6 нчы, 7 нче номерлы Кушымталар) нигезләнеп, белдермәнамәләрнең реестрын, махсус исәпләрнең реестрын алып бара.

3.7. ТР ДТИ Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына һәм өлкәара оператор адресына, ай саен хисап аеннан соң килүче айның 5 нче көненә кадәр, теркәлүче формалар (8 нче номерлы Кушымта) буенча, капиталь ремонт фондын булдыру ысулы сайланмаган күпфатирлы йортлар турындагы мәгълүматны юллый.

3.8. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе капиталь ремонт фондын булдыруга карата контроль турындагы белешмәләрне башкарма хакимиятнең Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль оешмаларның социаль-икътисади үсеше, төзелеш, архитектура, шәһәр төзелеше

һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм башкару һәм норматив-хокукый көйләү функциясен башкаручы федераль органына, әлеге федераль орган билгеләгән тәртиптә тапшыра.

1 нче номерлы Кушымта

Татарстан Республикасының
Дәүләт торак инспекциясенә

______________________________________________
(почта адресы)

**_________________________________________ адресы буенча күпфатирлы йортның капиталь ремонтына өлкәара оператор исеменә ачылган махсус исәп хуҗасы яисә махсус исәп хуҗасы тарафыннан махсус банк исәбе ачылу турында**

**БЕЛДЕРМӘНАМӘ**

***(исәпне ачканнан соң 5 көннән дә соңга калмыйча җибәрелә)***

«______» ______________ 20_____ел.

Оешу-хокукый формасы: ________________________________________
(ИК; ТМШ (30 ф. артык); ТМШ (30 ф. ким); ТТК; турыдан-туры идарә итү)

Махсус исәпнең хуҗасы: ______________________________________________
______________________________________________
(оешманың тулы исеме)

ИНН______________________________КПП______________________________

ОКАТО___________________________ОГРН______________________________

Махсус банк исәбе ачылу турында хәбәр итә:

Банк______________________________________________
(Банкның тулы исеме)

Банкның ИНН ______________________
Банкның КПП ______________________
Банкның ОГРН ______________________
Банкның БИК ______________________
Банкның корреспондент исәбе ________________________

Махсус исәпнең номеры ____________________________

Махсус исәпнең ачылу көне
«_____»____________________20_____ел.

Махсус исәп хуҗасы
оешмасының
җитәкчесе______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
(вазыйфасы, ФИА, имзасы)

МУ

Кушымта:
1. Әлеге күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт фондын булдыру ысулын сайлау турында карар кабул итү буенча гомуми җыелыш беркетмәсенең 1 нөсх. күчермәсе.
2. Махсус исәп ачылу турындагы банк белешмәсенең 1 нөсх. күчермәсе.

2 нче номерлы
Кушымта

**Капиталь ремонт фондын булдыру буенча**
**биналарның милекчеләренең гомуми җыелышының**
**____ номерлы БЕРКЕТМӘсе**
***(Үрнәк форма)***

**түбәндәге адрес буенча**________________________________________________

**«___»______ 20___ел.**

Җыелышның инициаторы ______________________________
Катнашты: ____ кеше (милекче).
Чакырылучылар:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

**Көн тәртибе:**

1. Гомуми җыелышның рәисен, сәркатибен һәм хисаплау комиссиясен сайлау.
2. Капиталь ремонт өчен өлкәара оператор исәбенә, яисә махсус исәпкә, яисә өлкәара оператор исеменә ачылган махсус исәпкә кертемнәрне күчерү юлы белән капиталь ремонт фондын булдыру ысулын сайлау;
3. Капиталь ремонт өчен айлык кертемнең күләмен билгеләү (торак бинаның $м^2$ нан);
4. Йортның минималь капиталь ремонт фонды күләмен билгеләү;
5. Күпфатирлы йортның гомуми милкен файдаланудан алынган табышларны капиталь ремонт фондын булдыруга юнәлтү;
6. Күпфатирлы йортның гомуми милкен капиталь ремонтлау буенча капиталь ремонт фонды хисабына финансланучы эшләрнең, хезмәтләрнең исемлеген раслау;
7. Капиталь ремонтны үткәрүнең вакытларын раслау.

Биналарның милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт өчен өлкәара оператор исәбенә, яисә махсус исәпкә, яисә өлкәара оператор исеменә ачылган махсус исәпкә кертемнәрне күчерү юлы белән капиталь ремонт фондын булдыру ысулы сайланган очракта:

а) махсус исәпне ачуга, яисә өлкәара оператор исеменә махсус исәп ачуга вәкаләтле һәм махсус исәптә, яисә өлкәара оператор исеменә ачылган махсус исәптәге акча чараларына бәйле операцияләрне башкаруга вәкаләтле затны;

б) махсус исәп ачылган, яисә өлкәара оператор исеменә ачылучы махсус исәп булган кредит оешмасын

сайлау буенча карар кабул итәргә кирәк.

**Тавыш бирделәр:**

1. Гомуми җыелышның рәисе итеп ______ сайларга,
   Гомуми җыелышның сәркатибе итеп ______ сайларга,
   Гомуми җыелышның хисаплау комиссиясен
   ____________,
   ____________,
   ____________ составында сайларга.

2. Капиталь ремонт өчен өлкәара оператор исәбенә, яисә махсус исәпкә, яисә өлкәара оператор исеменә ачылган махсус исәпкә кертемнәрне күчерү юлы белән капиталь ремонт фондын булдыру ысулын сайлау буенча тавыш бирделәр:

| Өлкәара оператор | Махсус исәп | Өлкәара оператор исеменә ачылган | Тавыш бирми калдылар |
|---|---|---|---|

| | | махсус исәп | |
|---|---|---|---|
| ________ тавыш | ________ тавыш | ________ тавыш | ________ тавыш |
| ________ % | ________ % | ________ % | ________ % |

__________ карары кабул ителде.

3. Капиталь ремонт өчен айлык кертемнең күләмен билгеләү (торак бинаның $м^2$ нан) буенча тавыш бирделәр:
   «Уңай» -
   «Каршы» -
   «Тавыш бирми калды» -

4. Йортның минималь капиталь ремонт фонды күләмен билгеләү буенча тавыш бирделәр:
   «Уңай» -
   «Каршы» -
   «Тавыш бирми калды» -

5. Күпфатирлы йортның гомуми милкен файдаланудан алынган табышларны капиталь ремонт фондын булдыруга юнәлтү буенча тавыш бирделәр:
   «Уңай» -
   «Каршы» -
   «Тавыш бирми калды» -

6. Күпфатирлы йортның гомуми милкен капиталь ремонтлау буенча капиталь ремонт фонды хисабына финансланучы эшләрнең, хезмәтләрнең исемлеген раслау турында тавыш бирделәр:
   «Уңай» -
   «Каршы» -
   «Тавыш бирми калды» -

7. Капиталь ремонтны үткәрүнең вакытларын раслау турында тавыш бирделәр:
   «Уңай» -
   «Каршы» -
   «Тавыш бирми калды» -

Биналарның милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт өчен өлкәара оператор исәбенә, яисә махсус исәпкә, яисә өлкәара оператор исеменә ачылган махсус исәпкә кертемнәрне күчерү юлы белән капиталь ремонт фондын булдыру ысулы сайланган очракта:

а) Махсус исәпне ачуга, яисә өлкәара оператор исеменә махсус исәп ачуга вәкаләтле һәм махсус исәптә, яисә өлкәара оператор исеменә ачылган махсус исәптәге акча чараларына бәйле операцияләрне башкаруга вәкаләтле затны сайлау буенча тавыш бирделәр:
   «Уңай» -
   «Каршы» -
   «Тавыш бирми калды» -

б) Махсус исәп ачылган, яисә өлкәара оператор исеменә ачылган махсус исәп булган кредит оешмасын билгеләү буенча тавыш бирделәр:
   «Уңай» -
   «Каршы» -
   «Тавыш бирми калды» -

**Түбәндәге карарларга килделәр**:

3. Гомуми җыелышның рәисе итеп _____ сайларга,
   Гомуми җыелышның сәркатибе итеп _____ сайларга,
   Гомуми җыелышның хисаплау комиссиясен
   ____________,
   ____________,

___________ составында сайларга.

1. Капиталь ремонт фондын (өлкәара оператор исәбендәге, махсус исәпле, өлкәара оператор исеменә ачылган махсус исәпле) булдыру ысулын сайларга ______________________________________________________________;

(йортның капиталь ремонт фондын булдыруның сайланган ысулын күрсәтергә)

2. Капиталь ремонт өчен айлык кертемнәрнең күләмен расларга ___________________________ ______________________________________________________________;

(РФ субъектының норматив-хокукый акты белән билгеләнгән күләмдә, яисә РФ субъекты тарафыннан билгеләнгәнне артып китүче күләмдә)

ш.и. РФ субъектының норматив-хокукый акты белән билгеләнгәннең минималь күләменнән артып китүче өлешендәге кертем ___________________________________________тәшкил итә;

1. Йортның минималь капиталь ремонт фонды күләмен расларга ______________________ ______________________________________________________________;

(РФ субъекты белән билгеләнгән яисә аннан артып китүче)

ш.и. РФ субъектының норматив-хокукый акты белән расланган минималь фонд күләмен узып китүче өлешендә.

2. Күпфатирлы йортның гомуми кулланылыштагы милкен файдалануга тапшырудан алынган табышларны биналарның милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертемнәрен түләү йөкләмәләрен башкаруы хисабына йортның капиталь ремонт фондын булдыруга юнәлтергә _________________;

(карар кабул ителде /кабул ителмәде)

Күпфатирлы йортның гомуми кулланылыштагы милкен файдалануга тапшырудан алынган табышларны РФ субъекты тарафыннан билгеләнгән минималь күләмен артып китүче өлешендә, биналарның милекчеләренең капиталь ремонт өчен РФ субъекты билгеләгән минималь кертемнәрнең күләмен артып китүче өлешендәге кертемнәрне түләү йөкләмәләрен үтәве хисабына, йортның капиталь ремонт фондын булдыруга юнәлтергә ____________________;

(карар кабул ителде /кабул ителмәде)

3. Йортның капиталь ремонт фонды хисабына финансланучы күпфатирлы йортның гомуми милкен капиталь ремонтлау буенча эшләрнең, хезмәтләрнең исемлеген расларга:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________;

(өлкәара программада каралганнардан кимрәк була алмый)

ш.и. РФ субъекты билгеләгән минималь капиталь ремонт фонды күләмен артып китүче өлешендәге капиталь ремонт фонды хисабына финансланучы _________________;

(карар кабул ителде /кабул ителмәде)

4. Күпфатирлы йортның гомуми милкенә капиталь ремонт үткәрүнең вакытларын расларга

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(күрсәтелгән вакытлар өлкәара программада күрсәтелгәннәрдән соңрак була алмый).

Биналарның милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт өчен өлкәара оператор исәбенә, яисә махсус исәпкә, яисә өлкәара оператор исеменә ачылган махсус исәпкә кертемнәрне күчерү юлы белән капиталь ремонт фондын булдыру ысулы сайланган очракта, түбәндәгеләр буенча карар кабул итәргә кирәк:

а) Махсус исәпне ачуга, яисә өлкәара оператор исеменә махсус исәп ачуга вәкаләтле һәм махсус исәптә, яисә өлкәара оператор исеменә ачылган махсус исәптәге акча чараларына бәйле операцияләрне башкаруга вәкаләтле зат итеп

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________сайларга.

(ТМШ, ТТК исеме)

б) Махсус исәп ачылачак, яисә өлкәара оператор исеменә ачылган махсус исәп булачак кредит оешмасы итеп_______________________________________________________________

_______________________________________________________________________________сайларга;

(кредит оешмасының исеме)

Искәрмә:

* «Россия Федерациясенең Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында»гы 25.12.2012, 271-ФЗ номерлы Федераль законның 175 ст.:

1) “Күпфатирлы йорт белән идарә итүне башкаручы һәм бер күпфатирлы йорттагы яисә фатирларының күләме суммада утыздан артып китмәгән берничә күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре тарафыннан оештырылучы торак милекчеләре ширкәте, әгәр дә әлеге йортлар күчемсез милекнең дәүләт кадастрында булган документлар нигезендә гомуми чиккә ия булса һәм алар чигендә әлеге йортларның биналары милекчеләренең гомуми файдалануы өчен билгеләнгән инженер-техник тәэмин ителеш челтәрләре, инфраструктураның башка элементлары булган җир кишәрлекләрендә урнашса;

2) күпфатирлы йорт белән идарә итүне башкаручы торак кооперативы яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы

махус исәп хуҗасы була ала”.

** «Россия Федерациясенең Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында»гы 25.12.2012,271-ФЗ номерлы Федераль законның 170 ст.:

Күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре капиталь ремонт фондын булдыру рәвешендә аны махсус исәпле итеп булдыруны сайлаган очракта, күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләренең гомуми җыелыш карары белән түбәндәгеләр билгеләнергә тиеш:

1) капиталь ремонт өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый акты белән капиталь ремонт өчен билгеләнгән минималь кертемнән дә азрак булмаска тиешле айлык кертем күләме;

2) күпфатирлы йорттагы гомуми милекнең капиталь ремонтына капиталь ремонт буенча өлкәара программада каралган мондый хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең исемлеге составыннан да ким булмаган хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең исемлеге;

3) күпфатирлы йорттагы гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрүнең капиталь ремонт буенча өлкәара программада карлаган планлаштырылган вакытлардан да соңрак була алмаган вакытлары;

4) махсус исәп хуҗасы;

5) махсус исәп ачылачак кредит оешмасы. Әгәр дә махсус исәп хуҗасы итеп өлкәара оператор билгеләнсә, күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре тарафыннан сайланган кредит оешмасы Россия Федерациясенең тиешле субъекты территориясендә махсус исәпләрне ачу һәм алып бару эшчәнлеген башкарырга тиеш. Әгәр дә күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре махсус исәп ачылырга тиешле кредит оешмасын сайламаган булса, яисә әлеге кредит оешмасы 271 номерлы ФЗ күрсәтелгән таләпләргә җавап бирмәсә, махсус исәп ачылырга тиешле кредит оешмасы турындагы мәсьәлә өлкәрә оператор карамагына тапшырылган булып санала.

*** РФ ТК 44 ст. 1.1 п. нигезендә күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләренең гомуми җыелышы компетенциясенә түбәндәгеләр карый:

1.1) капиталь ремонт фондын булдыруның ысулын, капиталь ремонт өчен кертем күләмен, капиталь ремонт фондының аның билгеләнгән минималь күләменнән артып китүче өлешендә минималь капиталь ремонт фонды күләмен (Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә минималь капиталь ремонт фонды күләме

билгеләнгән очракта), махсус исәп ачуга һәм махсус исәптәге акча чараларына бәйле операцияләрне башкаруга вәкаләтле затны сайлау буенча карар кабул итү.

**** РФ ТК 46 ст. 1 ө. нигезендә күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләренең тавыш куюга тәкъдим ителгән мәсьәләләр буенча гомуми җыелышы карарлары әлеге җыелышта катнашучы күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләренең барлык саныннан күпчелек алынган тавыш белән кабул ителә, әлеге Кодексның 44 статьясының 2 өлешендәге 1-3.1 пунктларында каралган, күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләренең гомуми саныннан өчтән ике өлешеннән дә ким булмаган тавышына карап кабул ителүче карарлардан тыш. Шулай итеп, РФ ТК 44 ст. 2 ө. 1.1 п. буенча карарларны кабул итү өчен күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләренең гомуми саныннан 2/3 өлешеннән дә ким булмаган күләмдә тавыш кирәк.

**Кушымталар:**
1. Йорт хуҗаларының гомуми җыелышында катнашучыларның исемлеге ( фатирларның №, милектә булган биналарның гомуми мәйданын һәм милекчеләрнең имзаларын күрсәтеп).
2. ТМШ Идарәсе әгъзалары исемлеге.
3. Ревизия комиссиясе әгъзалары исемлеге.

(Барлык кушымталар беркетмәләр белән бергә тегелә һәм идарәче оешманың мөһере, рәиснең һәм җыелыш сәркатибенең имзалары белән рәсмиләштерелә).

Әлеге беркетмә _____ нөсхәдә башкарылды.

3 номерлы Кушымта

Приложение № 1 к Приказу ФНС РФ от 09.06.2011 № ММВ-7-6/362@

1000 9017

ИНН

КПП     Бит 0 0 1

**Форма № С-09-1**

КНД 1110009     **буенча код**

салым органы коды

**ХЂБЂРНАМЂ**
**ИСЂПНЕ (ШЂХСИ ИСЂПНЕ) АЧУ (ЯБУ) ТУРЫНДА**

1 - Россия оешмасы
2 - чит ил оешмасы
3 - Россия Федерациясе территориясендђ аерымланган бњлекчђ аша эшчђнлек алып баручы чит ил оешмасы
4 - шђхси эшмђкђр
5 - шђхси практика белђн шљгыльлђнњче нотариус,адвокат кабинетын оештыручы адвокат

(оешманыћ исеме, шђхси эшмђкђрнећ, шђхси практика белђн шљгыльлђнњче нотариусныћ, адвокат кабинетын оештыручы адвокатныћ фамилиясе, исеме, атасыныћ исеме)

ОГРН     ОГРНИП     КИО [1]

Хђбђр итђ
1 - исђп ачылу турында
2 - исђп ябылу турында

1 - банкта
2 - Федераль казначылык органында (шђхси исђплђрне ачуны цђм алып баруны башкаручы башка органда)

Ђлеге хђбђрнамђ 2 биттђ тљзелд     документларныћ књчермђлђрен теркђп     нњсхђдђ

**Ђлеге хђбђрдђ књрсђтелгђн белешмђлђрнећ дљреслеген цђм тулылыгын раслыйм:**

1 - шђхси эшмђкђр (шђхси практика белђн шљгыльлђнњче нотариус, адвокат кабинетын оештыручы адвокат)
2 - шђхси эшмђкђрнећ вђкиле (шђхси практика белђн шљгыльлђнњче нотариусныћ, адвокат кабинетын оештыручы адвокатныћ)[2]
3 - оешманыћ китђкчесе (Россия Федерациясе территориясендђ оештырылган чит ил оешмасыныћ аерымланган бњлекчђсенећ)
4 - оешма вђкиле (Россия Федерациясе территориясендђ оештырылган чит ил оешмасыныћ аерымланган бњлекчђсенећ)[2]

(оешма китђкчесенећ яисђ вђкиленећ тулы фамилиясе, исеме, атасыныћ исеме)

ИНН [3]

Элемтђ телефоны номеры

E-mail

(имза)     (дата)

М.П.

Вђкилнећ вђкалђтлђрен раслаучы документныћ исеме

**Салым органы хезмђткђре тарафыннан тутырыла**

Хђбђрне тапшыру турында белешмђлђр

Ђлеге хђбђр тапшырылды (код)

2 биттђ

документ књчермђлђрен теркђп     биттђ

Хђбђрне тапшыру кљне . .

Ђлеге номер белђн теркђлде

(Фамилия, И.А.)     (Имза)

[1] Чит ил оешмасы љчен (ИНН булмаганда)

[2] хђбђргђ вђкилнећ вђкалђтлђрен раслаучы документ књчермђсе теркђлђ

[3] ИНН бирелњне раслаучы документы (салым органында исђпкђ куелу турындагы таныклык, Россия Федерациясе гражданины паспортындагы тамга) цђм шђхси мђгълњматлары белђн берлектђ кулланылучы ИНН булган физик затларга карата тутырыла.

1000 9031

ИНН

КПП

Бит. 002

Б БИТЕ

**Федераль казначылык органында (шђхси исђплђрне ачуны џђм алып баруны башкаручы башка органда) ачылган (ябылган) шђхси исђп турындагы белешмђлђр**

Исђп №

Исђпнеђ ачылу/ябылу кљне . .

Федераль казначылык органы (шђхси исђплђрне ачуны џђм алып баруны башкаручы башка орган) турындагы белешмђлђр

ИНН КПП

( Федераль казначылык органыныђ (шђхси исђплђрне ачуны џђм алып баруны башкаручы башка органныђ) исеме)

**Федераль казначылык органына (шђхси исђплђрне ачуны џђм алып баруны башкаручы башка органга) ачылган банк исђбе турындагы белешмђлђр**

Исђп №

Банк турындагы белешмђлђр

(банкныђ исеме)

Урнашкан урыны

Почта индексы Љлкђ коды

Район

Шђџђр

Торак пункт

Урам (проспект, тыкрык џ.б..)

Йорт (билђмђ) номеры Корпус (корылма) номеры Офис номеры

ИНН КПП БИК

**Монда кљрсђтелгђн белешмђлђрнеђ тулылыгын џђм дљреслеген раслыйм:**

(имза)

1000 9024

ИНН

КПП Бит. 002

А БИТЕ

**Исђпне ачуны (ябуны) башкарган банктагы исђп турындагы белешмђлђр**

Исђп № Исђпнеђ ачылу/ ябылу кљне . .

( банкныђ исеме)

Урнашкан урыны

Почта индексы Љлкђ коды

Район

Шђђђр

Торак пункт

Урам (проспект, тыкрык ћ.б.)

Йорт (билђмђ) номеры Корпус (корылма) номеры

ИНН КПП БИК

**Монда књрсђтелгђн белешмђлђрнеђ дљреслеген ђђм тулылыгын раслыйм**

(имза)

4 нче номерлы Кушымта

**____________________________________________ адресы буенча**

**күпфатирлы йортта идарә итү ысулын**
**сайлау буенча гомуми җыелышның ___ номерлы**
**Беркетмәсе**

Казан ш. «__» _________ 20__ ел.

Беркетмәне төзегәндә катнаштылар:
Түбәндәгеләр составында хисаплау комиссиясе:
___ номерлы фатир хуҗасы - *ФИА*_____ (Казан шәһәренең *Исеме* районы Техника инвентаризациясе бюросында ___ номеры белән теркәлүче торак бинаны гражданнарга милек итеп тапшыруга карата килешү, __.__.____ел.)

___ номерлы фатирның хуҗасы - *ФИА*_______( __.__.____ елдан, ААХ сер. ___ номерлы, Федераль теркәү хезмәтенең ТР буенча баш идарәсендә теркәлгән хокукый милек турындагы таныклык)

Җыелышның инициаторы – ___ номерлы фатирның хуҗасы - __*ФИА*______(Казан шәһәренең *Исеме* районы Техника инвентаризациясе бюросында ___ номеры белән теркәлүче торак бинаны гражданнарга милек итеп тапшыруга карата килешү, __.__.____ел.)

Читтән торып тавыш бирү буенча белдермәнамәләр милекчеләргә тапшырылды «__» _______ 20__ел.
Читтән торып тавыш бирү тәмамланды «__» ________ 20__ел.
Читтән торып тавыш бирү турында барлыгы 100% белдермәнамә тапшырылды.

Күпфатирлы йорттагы биналарның гомуми мәйданы _______ кв. м.
Күпфатирлы йорттагы торак биналарның гомуми мәйданы ________ кв. м.
Читтән торып тавыш бирүдә ____ милекче катнашты, алар _______ кв. м мәйданга ия, бу күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләренең гомуми тавыш саныннан ____% тәшкил итә.
Читтән торып тавыш бирү карары буенча тавышларны исәпләү нәтиҗәсендә гомуми җыелышның карары тулы хокуклы санала.

**Көн тәртибе:**
1. Җыелышның рәисен, сәркатибен һәм хисаплау комиссиясенең әгъзаларын сайлау турында.
Җыелышның рәисе буларак тәкъдим ителүче кандидатура – __ номерлы фатир хуҗасы - __*ФИА*.
Җыелышның сәркатибе буларак тәкъдим ителүче кандидатура – __ номерлы фатир хуҗасы - *ФИА*.
Хисаплау комиссиясе әгъзалары буларак тәкъдим ителүче кандидатуралар - __ номерлы фатир хуҗасы - *ФИА*.
__ номерлы фатир хуҗасы - *ФИА*.
__ номерлы фатир хуҗасы - *ФИА*.
2. Идарә итү ысулын сайлау турында:
а) ТМШ;
б) идарәче оешма;
в) турыдан-туры идарә итү;
3. Идарәче оешманы сайлау – *Идарәче оешманың исеме;*
4. *Идарәче оешманың исеме* килешү проекты редакциясендә күпфатирлы йорт белән идарә итүнең килешү шартларын кабул итү турында.
5. Күпфатирлы йортның гомуми җыелыш нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлары турында биналарның милекчеләренә хәбәр ирештерү тәртибе турында.
6. Биналарның милекчеләренең гомуми җыелышларының беркетмәләрен һәм карарларын саклау урынын билгеләү турында.

**Сайлауда күтәрелгән мәсьәләләр:**
1. **Җыелышның рәисен - *ФИА* сайлау буенча тавыш бирделәр**:
Уңай - ___% тавыш, каршы - ___% тавыш, тавыш бирми калды - ___% тавыш
Карар кылдылар: җыелышның рәисе итеп *ФИА* сайларга.
**Сәркатипне - *ФИО* сайлау буенча тавыш бирделәр**.
Уңай - ___% тавыш, каршы - ___% тавыш, тавыш бирми калды - ___% тавыш
Карар кылдылар: җыелышның сәркатибе итеп *ФИО* сайларга.

**Хисаплау комиссиясен** *ФИО,ФИО.* **составында сайлау турында тавыш бирделәр:**
Уңай - катнашучыларның тавышларыннан ___% тавыш, каршы – катнашучларның тавышларыннан ___% тавыш, тавыш бирми калды - катнашучыларның тавышыннан ___% тавыш.
Карар кылдылар: *ФИО,ФИО.* составында хисаплау комиссиясен сайларга.

2. **Идарә итү ысулын сайлауда тавыш бирделәр.**

- ТМШ

Уңай - катнашучыларның тавышларыннан ___% тавыш, каршы – катнашучларның тавышларыннан ___% тавыш, тавыш бирми калды - катнашучыларның тавышыннан ___% тавыш.

- Идарәче оешма

Уңай - катнашучыларның тавышларыннан ___% тавыш, каршы – катнашучларның тавышларыннан ___% тавыш, тавыш бирми калды - катнашучыларның тавышыннан ___% тавыш.

- Турыдан-туры идарә итү

Уңай - катнашучыларның тавышларыннан ___% тавыш, каршы – катнашучларның тавышларыннан ___% тавыш, тавыш бирми калды - катнашучыларның тавышыннан ___% тавыш.

3. *Идарәче оешманың исеме* - **Идарәче оешманы сайлау буенча тавыш бирделәр.**
Уңай - катнашучыларның тавышларыннан ___% тавыш, каршы – катнашучларның тавышларыннан ___% тавыш, тавыш бирми калды - катнашучыларның тавышыннан ___% тавыш.
Карар кылдылар: *Идарәче оешманың исеме* – идарәче оешмасын сайларга.

4. *Идарәче оешманың исеме* – **килешү проекты редакциясендәге күпфатирлы йорт белән идарә итү килешүе шартларын кабул итү турында тавыш бирделәр**:
Уңай - катнашучыларның тавышларыннан ___% тавыш, каршы – катнашучларның тавышларыннан ___% тавыш, тавыш бирми калды - катнашучыларның тавышыннан ___% тавыш.
Карар кылынды: *Идарәче оешманың исеме* – килешү проекты редакциясендәге күпфатирлы йорт белән идарә итү килешүе шартларын кабул итәргә.

5. **Күпфатирлы йортның гомуми җыелыш нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлары турында биналарның милекчеләренә хәбәр ирештерү тәртибе буенча тавыш бирделәр:**
Уңай - катнашучыларның тавышларыннан ___% тавыш, каршы – катнашучларның тавышларыннан ___% тавыш, тавыш бирми калды - катнашучыларның тавышыннан ___% тавыш.
Карар кылдылар: күпфатирлы йортның гомуми җыелыш нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлары турында биналарның милекчеләренә хәбәр итүне ___ көн дәвамында күпфатирлы йортның беренче подъездындагы керү юлында (ишекләрендә) кабул ителгән карар турындагы беркетмә күчермәсен урнаштыру юлы белән башкарырга.

6. **Беркетмәләрне саклау буенча түбәндәге адресларда урнашкан урыннарны билгеләүгә карата тавыш бирделәр:** *Идарәче оешманың исеме – җыелышның инициаторында.*
Уңай - катнашучыларның тавышларыннан ___% тавыш, каршы – катнашучларның тавышларыннан ___% тавыш, тавыш бирми калды - катнашучыларның тавышыннан ___% тавыш.
Карар кылдылар: әлеге беркетмә ___ нөсхәдә төзелде:
- карар белән беркетмәнең бер нөсхәсе *Идарәче оешманың исеме* саклана,
- беркетмәнең икенче нөсхәсе җыелышның инициаторында саклана,
Әлеге беркетмә ________________________________ буенча ___ номерлы күпфатирлы йорт милекчеләренә «___» ______________20 __ елга кадәр җиткерелергә тиеш.

Хисаплау комиссиясе:
Рәисе: ___________________________*ФИА.*
Җыелышның сәркатибе ____________________________ *ФИА.*
Комиссиянең әгъзасы: ____________________________ *ФИА.*

5 нче номерлы Кушымта

| 0401060 |
|---|

Банкка кучкән түләү — Түл. исәб. кучерелгән

ТҮЛӘҮ ЙӨКЛӘМӘСЕ N

Дата — Түләү төре

| | | | |
|---|---|---|---|
| Сумма хәреф белән | | | |
| ИНН | КПП | Сумма | |
| Түләүче | | Ис. N | |
| Түләүченең банкы | | БИК | |
| | | Ис. N | |
| Алучының банкы | | БИК | |
| | | Ис. N | |
| ИНН | КПП | Ис. N | |
| Алучы | | Түл. төре. | Түл. вакыты. |
| | | Түл.бил. | Чир. түл. |
| | | Код | Рез.юл |

Түләүнең билгеләнеше

имзалар — Банк тамгалары

М.У.

6 нчы номерлы Кушымта

Биналарның милекчеләре тарафыннан сайланган капиталь ремонт фондын булдыру ысулы турындагы хәбәрнамәләр
РЕЕСТРЫ
2013 елның "__"________ карата хисап

| Муниципаль оешма | Адресы | Махсус исәп хуҗасының исеме | Почта адресы | ОГРН | ИНН | ОКАТО | КПП | ДТИ теркәлү көне | ДТИ теркәлү номеры | Хәбәр итү көне | КР фонды (махсус исәп, төбәкара оператор исеменә ачылган махсус исәп) | Милекчеләрнең фонд булдыру ысулын сайлауга карата карар кабул итү буенча гомуми җыелышы беркетмәсенең көне | Махсус исәпнең ачылу көне |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 14 | 15 |

7 нче номерлы Кушымта

2013 елның "__"________ карата
махсус исәпләрнең
реестры

| Муниципаль оешма | Адресы | Махсус исәп хуҗасының исеме | Махсус исәпнең № | Ачу көне | Ябу көне | Банк исеме | Банкның почта адресы | Банкның ИНН | Банкның КПП | Банкның ОГРН | Банкның БИК | Банкның корреспондент исәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |

8 нче номерлы Кушымта

Биналарының милекчелҙре капиталь ремонт фондын булдыру ысулын сайламаган

КФЙ турында БЕЛЕШМҘЛҘР

2013 елның "__" ________ карата хисап.

| № | Муниципаль оешма | Адресы | Идарҙче оешманың оешу-хокукый формасы | Идарҙче оешманың тулы исеме |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |